КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 август г.Казань № 667

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләр китапханәләренең китап фондларын туплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 1 октябрь, 706 нчы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иҗади эшчәнлеккә ярдәм итү һәм халык саны 300 мең кешегә кадәр булган торак пунктларда муниципаль театрларның матди-техник базасын ныгыту өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 29 октябрь, 969 нчы карары белән расланган Иҗади эшчәнлеккә ярдәм итү һәм халык саны 300 мең кешегә кадәр булган торак пунктларда муниципаль театрларның матди-техник базасын ныгыту өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның «б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктта:

беренче абзацта «муниципаль берәмлек» сүзләрен «муниципаль берәмлек ($C_i$)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктта «Министрлык тарафыннан расланган формалар» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта:

өченче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап бирү формасы һәм сроклары;»;

алтынчы абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар килешүдә билгеләнгән срокларда муниципаль берәмлекләрнең финанс органнары өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетларына күчерелә.»;

16 пунктның беренче абзацында «башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап» сүзләренә алмаштырырга, «Министрлык тарафыннан билгеләнә торган формалар һәм тәртип буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта:

беренче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече» сүзләрен «бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктның беренче абзацында «башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктта:

дүртенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенең» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенең» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы авыл мәдәният учреждениеләренә һәм авыл мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 31 октябрь, 983 нче карары белән расланган Иң яхшы авыл мәдәният учреждениеләренә һәм авыл мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның «б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктта:

беренче абзацта «муниципаль берәмлек» сүзләрен «муниципаль берәмлек ($C_i$)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

12 пунктта «Министрлык тарафыннан расланган формалар» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта:

өченче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап бирү формасы һәм сроклары;»;

алтынчы абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар килешүдә билгеләнгән срокларда муниципаль берәмлекләрнең финанс органнары өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетларына күчерелә.»;

15 пунктның беренче абзацында «башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап» сүзләренә алмаштырырга,

«Министрлык тарафыннан билгеләнә торган формалар һәм тәртип буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта:

беренче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече» сүзләрен «бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктның беренче абзацында «башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктта:

дүртенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенең» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенең» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни-ял чараларын үткәрү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 20 июль, 620 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 август, 844 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Мәдәни-ял чараларын үткәрү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

8 пунктта «Министрлык тарафыннан расланган форма» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта:

дүртенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «тәртибе» сүзеннән соң «һәм сроклары» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап бирү формасы һәм сроклары;»;

җиденче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «күчерү» сүзеннән соң «килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә муниципаль берәмлекләрнең финанс органнары тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә ачылган» сүзләрен өстәргә;

11 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Вәкаләтле орган, хисап кварталыннан соң килә торган айның 5еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турындагы хисапны һәм башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турындагы хисапны (электрон төрдә һәм кәгазьдә) Министрлыкка кертә.»;

12 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга, «чара үткәрү» сүзләрен «чаралар үткәрү» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече зурлыгына ирешүне» сүзләрен «бирү нәтиҗәлелеген» сүзләренә алмаштырырга, «нәтиҗәлелек күрсәткече» сүзләрен «башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның беренче абзацында «башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече зурлыгына ирешү турында хисап» сүзләрен «башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисаплылык» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта:

дүртенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенең» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенең» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләр китапханәләренең китап фондларын туплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 1 октябрь, 706 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин